| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

9 август 2019 ел №17

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 23 октябрендәге 47 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында (2017 елның 30 маендагы 12номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 26 номерлы үзгәрешләре белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 391, 394нче статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районыны «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 23 октябрендәге 47 номерлы «Җир салымы турында» Карарына (2017 елның 30 маендагы 12 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 26 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 3нче пункт 5нче абзац үз көчен югалткан дип танырга;
б) 5.1 пунктның 2, 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар салым органында юк, шул исәптән салым түләүченең салым ташламасын бирү турында салым түләүченең гаризасында күрсәтелгән мәгълүмат буенча салым органы салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы белешмәләрне соратып ала.
Салым органының салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган белешмәләрне тапшыру турында салым органы яисә башка зат аны алганнан соң җиде көн эчендә яки шул ук вакытта салым органына запросның үтәлмәү сәбәпләре турында хәбәр итә.»;

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының « Түбән Чыршылы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2015 елның 23 октябрендәге 47номерлы “Җир салымы турында”карарына үзгәрешләр кертү турында» (2017 елның 30 маендагы 12, 2018 елның 14

декабрендәге 26 номерлы үзгәрешләре белән), 2019 елның 5 июнендәге 15 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Түбән Чыршылы авылында урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) “Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай үткәннән соң гына үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башлыгы
Совет Рәисе Н.Я. Хәйруллина